КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 август г.Казань № 663

Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт архивларының гомумтармак эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак җитәкче, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләренең әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы хезмәткә түләү системасы нигезендә түләнә торган әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләүнең яңа шартларына күчкәндә гамәлдә булган хезмәт хакыннан ким була алмый дип билгеләргә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм алар тарафыннан шул ук квалификацияне үтәү шарты белән.

3. «Татарстан Республикасының Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесенә «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениеcе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2016 ел, 22 сентябрь, 676 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2016 ел, 22 сентябрь, 676 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 28 октябрь, 794 нче.

5. Бу карарның гамәле рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә һәм  2019 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин